ЭШЛӘГӘНГӘ – ЭШ

Кайбыч фермеры Гөлназ Щукина бүгенге вазгыятьтән курыкмый, яхшыга өметләнә

> 2

ЭШЛЕКЛЕ ЮБИЛЕЙ

Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгы бәйрәм белән генә чикләнми

> 3

УПКЫН ЧИТЕНДӘ

«Рубин» рәттән өченче тапкыр оттырып, тагын да аскарак төште

> 4

ӘЛИФБА ТАВЫ

Самара өлкәсендәге Татар Байтуганы авылында халыкны магнит кебек тартып торучы урыннар бар

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 47 (28820) | Сишәмбе | 5 апрель | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

«КАЙТЫР ИДЕМ, ӨЕМ ЮК...»

ТАТАРСТАН МӘҖБҮРИ ЭВАКУАЦИЯЛӘНҮЧЕЛӘРНЕ КАРШЫ АЛДЫ

Ярдәм янәшә!

Ерак һәм берничә тәүлеккә сузылган юлдан соң, Татарстанга Украина, Донецк һәм Луганск халык республикаларыннан мәҗбүри эвакуацияләнүчеләр поезды кайтты. Кайсылары поезддан чыгуга кунакчыллык күрсәткән республиканы рәхмәт сүзләренә күмде, кемнәр моңсу елмайды. Артта – элеккеге тормыш, алда билгесезлек көтә чөнки. Шунысы бәхәссез: билгесезлек упкынында да ярдәм кулы сузучылар бар.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Шартлар тудырылган

1 апрель төненең яңа көнне менә-менә башлыйм дигән мәлендә Казан тимер юл станциясендә Таганрогтан поезд көтәләр. Волонтерлар, Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы вәкилләре, хокук сакчылары Украина, Донецк һәм Луганск халык республикаларыннан мәҗбүри эвакуацияләнүчеләрне каршы алырга әзерләнә. Вокзалны аерылышу-кавышу урыны дип беләбез. Ә бу көнне ул 502 кеше (5 яңа туган сабый, 99 бала, 168 ир-ат һәм 230 хатын-кыз) өчен билгесезлек чиген атлап чыгу урыны булгандыр. Күпләренең өс-башы да, кулларындагы төенчекләре дә әллә ни түгел. Хәер, ут эченнән кулга эләккән беренче әйберне алып чит якка чыгып киткәндә кием-салым кайгысы булганмы инде аларда? Йөзләрендә – курку да, ниһаять, тыныч җиргә аяк басуларына куану чаткылары да, бәлки әле киләчәккә дигән өмет тә чагылып ала… Күченеп кайтучылар арасында мөмкинлекләре чикле кешеләр дә күренә. Поезддан шундый дистәләгән кеше төште. Андыйларга волонтерлар махсус колясскалар белән ярдәмгә ашыкты.

Тормышлары «кичә» һәм «бүген»гә бүленгән әби-бабайлар, тулы гаиләләр, балалар һәм хәтта дүрт аяклы иптәшләрне Татарстан җирендә җиде юл чатында ташлап калдырырга җыенмыйлар.

– Барысы да вакытлыча яшәү урыннарына урнаштырылачак. Анда барлык шартлар да тудырылган, кирәк-яраклар бар. Ихтыяҗ булса, медицина ярдәме күрсәтеләчәк, табиблар хроник чирләргә һәм коронавируска тикшерәчәк, – дип ышандырды Татарстан Премьер-министры беренче урынбасары Рөстәм Нигъмәтуллин.

Кыен хәлдә калганнар «Санта», «Жемчужина», «Васильевский», «Ливадия» шифаханәләре һәм «КамАЗ-жилбыт», «Кварт» кунакханәләрендә сыену таба. Балалар бакчасыз, мәктәпсез калмаячак, эшләргә теләге булганнарны республиканың 400 предприятиесе эш белән тәэмин итәргә әзер. Бу хакта «эшлекле дүшәмбе» вакытында Казан мэры Илсур Метшин да әйтте.

– Кайтучылар арасында техника иярләргә әзер кешеләр дә бар. Эшче куллар кирәк. Әйтик, безнең «Водоканал», «Казэнерго», социаль оешмаларда, шәһәрне төзекләндерү предприятиеләрендә ихтыяҗ бар. Белеме һәм күнекмәләре булганнарны эш белән тәэмин итәчәкбез, – диде ул.

– Вакытлыча яшәү урыннарында күченеп кайтучылар өчен психолог эшләячәк. Моннан тыш, беренче көннәрдә безнең тармак хезмәткәрләре дә кизү торачак, – диде Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан буенча идарәсе башлыгы Рафис Хәбибуллин.

Күченеп кайтучыларның Татарстанда күпме яшәячәкләре билгеле түгел. Аларның көнкүрешен оештыру өчен акча федераль бюджеттан бүлеп бирелә.

2 апрельдә исә Татарстанга тагын 486 кешелек поезд кайтты. Алар арасында 112 бала, 32 мөмкинлекләре чикле кеше бар иде. Биш кешегә медицина ярдәме кирәк булды, аларны шундук республика хастаханәләренә урнаштырдылар.

Ахыры 2 нче биттә >

САН

Апрель аенда Россия территориясенә Украина, Донецк һәм Луганск халык республикаларыннан 50 меңләп кеше килгән. Шулай итеп, ил эчендәге мәҗбүри эвакуацияләнүчеләрнең саны 598 меңнән артты. Шуларның 118 меңе – балалар. Кыен хәлдә калганнарның 170 меңе Россия гражданлыгына ия, 340 меңе – Донецк һәм Луганск халык республикаларыннан, 83 меңе – Украина халкы.
Билгеле булганча, аларга 10 мең сум күләмендә түләү каралган.

Республика 2 миллион сум бирә

Украинада махсус хәрби операция барышында һәлак булган Татарстан хәрбиләренең гаиләләре өстәмә матди ярдәм алачак. Республика Президенты Рөстәм Миңнехановның кул куйган Указ нигезендә, якыннарын югалткан гаиләләргә бер тапкыр икешәр миллион сум биреләчәк. Ватан алдындагы бурычын каһарманнарча үтәгәндә һәлак булган хәрбиләрнең гаиләләре өчен өстәмә финанс ярдәме булачак бу.

Исегезгә төшерәбез: моңа кадәр Россия Президенты Владимир Путин Украинада махсус операция вакытында гомере өзелгән барлык хәрбиләрнең гаиләләренә иминишт акчасы һәм бер тапкыр бирелә торган акча – 7 миллион 421 мең сум күчереләчәген хәбәр иткән иде. Моннан тыш һәлак булган хәрбинең гаиләсенең һәрбер әгъзасына айлык акчалата компенсация түләнеләчәк.

Унынчы ифтарга – ун мең кеше

Татарстан мөселманнары 30 апрельдә республика күләмендәге ифтарга җыелачак. Быел ул унынчы тапкыр уздырыла. Ифтар мәҗлесе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгы уңаеннан оештырыла. Чараны Диния нәзарәте, «Ак барс Арена» стадионы дирекциясе һәм «Туган авылым» милли-туристлык комплексы үткәрә.

Республика күләмендәге унынчы ифтар барлыгы 10 мең кешене кабул итәчәк. Чара, алдагы елдагы кебек үк, «Казан ЭКСПО» халыкара күргәзмә үзәгендә үткәреләчәк. Ифтарда катнашучыларны, гадәттәгечә, бай мәдәни программа көтә. Мәҗлес кунакларын каршы алу, күмәк намаз укуны оештыру, ризык өләшү һәм ифтар тәмамланганнан соң табынны җыештыру өчен 16 яшьтән зуррак 500 волонтер җәлеп ителәчәк. Саваплы хезмәтне башкаручылар сафына кушылу өчен +7 (843) 237-86-18 телефон номерына шалтыратырга мөмкин.

Туристлар көтәбез

Май бәйрәмнәрендә Казанга 100 меңнән артыграк туристның килүе көтелә. Бу чорда кунакханәләр 60–90 процентка тулачак, дип белдергән шәһәрнең Туризмны үстерү комитеты директоры Дарья Санникова.

Татарстан башкаласында барлыгы 229 кунакханә эшләп килә. Март аенда алар 52 процентка кунаклар белән тулса, май бәйрәмнәрендә кайберләре тулысынча тулган хәлдә эшләргә мөмкин. Санникова әйтүенчә, кешбэк программасы туристлар ташкыны арттыруга ярдәм иткән. Россия буйлап сәяхәт кылу өчен 15 марттан 9 апрельгә кадәр сатып алынган юллама (сәяхәт кылу чоры – 30 июньгә кадәр) бәясенең 20 процентын кире кайтару мөмкинлеге бар.

Сүз уңаеннан, гыйнвар – февраль айларында Казан Кремлендә – 357 меңнән артыграк, ә «Шәһәр панорамасы» музеенда 7 мең чамасы турист булып киткән.

kazan.aero

Көн кадагында

Тормыш көйләнеп килә

Татарстанда шикәр комы, ярма кебек ризыкларны сату күләме кимегән, әмма уртача куллану күләме барыбер гадәттәгедән күбрәк әле. Складлардагы төп товар запасы – барыбызга да җитәрлек дәрәҗәдә. Бу хакта вице-премьер – икътисад министры Мидхәт Шаһиәхмәтов Хөкүмәт йортында узган киңәшмәдә белдерде.

«Озак саклана торган продуктларны сату күләме алдагы атна белән чагыштырганда 10–25 процентка кимегән. Ихтыяҗ тотрыклылана башлаган, димәк. Яңа компанияләр белән килешүләр төзү, товар күләмен арттыру, бер кешегә сатылган товар күләмен чикләү ихтыяҗны киметүгә ярдәм итә», – диде ул. Республикада яшәүчеләрне кирәкле продукция белән тәэмин итү өчен Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы районнар белән берлектә язгы ярминкәләр үткәрә. Аларда арзанрак бәядән кирәкле барлык продуктларны сатып алырга мөмкин. Башка чаралар да күрелә. Әйтик, шикәр комын югары бәядән сатуның берничә очрагы ачыкланган. Хәзер аларны хокук сакчылары тикшерә.

Даруларга килгәндә, Мидхәт Шаһиәхмәтов әйтүенчә, узган атнада 2,6 айдан 5,2 айга кадәр җитәрлек товар запасы (барлыгы 4,8 миллиард сумлык) булдырылган. Хәзерге вакытта даруханәләрдә кирәкле барлык препаратлар бар. Даруханәләр челтәрендә товар белән тәэмин ителүгә һәм бәяләргә көн саен мониторинг үткәрелә.

Киңәшмәдә импортны алыштыру мәсьәләсе турында да сүз булды. Республика маркетинг үзәге, санкцияләр кертелү сәбәпле, базардан киткән товар белән тәэмин итүчеләр урынына яңаларын эзләү бурычын хәл итә. Ә инде Дәүләт заказы агентлыгы чит ил продукциясен алыштыру буенча тәкъдимнәр каталогын эшли. Бер атна эчендә якынча 3,4 мең төрдәге импорт продукциясен алыштыру буенча 9 меңнән артыграк тәкъдим кертелгән.

Республикада кредит каникулы программасын тормышка ашыру дәвам итә. Узган атнада кергән 498 гаризаның 184е хупланган (барлыгы 876 миллион сумга). Киңәшмәдә 14 районның бу программада катнашмавы турында җиткерделәр.

Шулай ук бизнеска ташламалы кредитлар бирелә. Әйтик, кече һәм урта эшмәкәрлек корпорациясенең «Инвестиционная» программасы буенча бер атна эчендә барлыгы 49 гариза (500 миллион сумга) тапшырылган. Россия Үзәк банкының «Оборотная» программасы буенча – 212 гариза (2,1 миллиард сумга). Барлыгы 35 гариза (375 миллион сумга) хупланган.

Моннан тыш узган атнада «Программа 1764» дигән ташламалы кредитлау программасы башланган. Анда 22 банк катнаша. Ташламалы кредитлар 15 процентлы ставка белән бирелә. Микропредприятиеләр өчен кредит күләме – 200 миллион сумга кадәр, кече предприятиеләр өчен – 500 миллион сумга кадәр, урта предприятиеләр өчен – 2 миллиард сумга кадәр.

Сүзгә-сүз

«Татар-информ»

Ләбиб ЛЕРОН, язучы:

Язучылар турында «безнең салым акчасына китап чыгаралар, очрашуларда бәлеш ашап йөриләр…» дип язалар. Үз машинамда, яныма өч-дүрт язучыны утыртып, рульдә йөреп кайтам икән, мин бит бәлеш ашарга дип бармыйм. Мин аны өйдә дә ашый алам. Кешене үсендереп торасы урынга аяк чалырга торучылар бар. Алга барып булмыйдыр да шул бердәмлек булмау аркасында.

(«Интертат»ка әңгәмәсеннән)

ТАТАРСТАНДА – ЯЗГЫ КЫР ЭШЛӘРЕ

ОРЛЫК
366 мең тонна бөртекле һәм кузаклы культура орлыгы әзерләнгән.
Кукуруз, көнбагыш, шикәр чөгендере орлыгы кайтару дәвам итә.

АШЛАМА
152 мең тонна ашлама тупланган.
1 гектарга уртача – 55,1 кг ашлама. Зәй һәм Тәтештә 100 килограммнан артык

ТЕХНИКА
Трактор, чәчкеч һәм культиваторларның **98 проценты** ремонтланган.
2,1 млрд сумлык запас частьлар сатып алынган.

Сөенечле хәбәр!

14 апрельгә кадәр «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына ташламалы бәядән язылып була!

П2435 җомга саны — Ташламалы бәя **423 сум 48 тиен**
гадәти бәясе – ~~488 сум 10 тиен~~

П2409 атнага дүрт тапкыр чыга — Ташламалы бәя **942 сум 18 тиен**
гадәти бәясе – ~~1099 сум 32 тиен~~

Реклама 16+

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ГАЗ – СУМНАРГА, САНКЦИЯЛӘР АРТА, КОРАЛЛАНУ КӨЧӘЯ

Үткән атнаның төп яңалыкларын без язманың исеменә чыгардык. Яңалыклар барысы да Украина кризисы тирәсендә бөтерелә. Хәтта ялларда Европадагы зур булмаган ике дәүләттә үткән сайлауларга да сәясәтчеләр шул кризис призмасыннан бәя бирәләр. Ике илдә дә Россия тарафдарлары җиңде. Сербиядә Президент урындыгын Вучич саклап калды, Венгриядә парламент сайлавында Орбан партиясе күпчелек тавышны алды. Мәскәү өчен кечкенә булса да уңай фон болар.

Газ төенен яклар икесен дә канәгатьләндерерлек формула табып чишеп киләләр. Сәүдә валютасы элеккечә диярлек кала, көнбатышлылар евро белән түлиләр, әмма – «Газпромбанк»ка. Соңгысы исә газ сатучыларга акчаны сумнарга әйләндереп күчерә. Европа Россия газыннан әле генә баш тарта алмый, чөнки күләме артык зур. Ул күләмнән баш тарту күтәрә алмаслык энергетик кризиска китерер иде. Әмма көнбатышлыларның стратегиясе – дошманга әйләнгән ил углеводородыннан акрынлап баш тарту.

Дөньяның мәгълүмат кырына Россия хәрбиләре үткән атнада калдырып киткән Буча шәһәрендәге вәхшәтнең фото һәм видеоматериаллары таралды. Чәчләрне үрә торгызырлык күренештә украиннар Россия хәрбиләрен гаепли. Россиянең Оборона министрлыгы әлеге фотоларны чираттагы провокация дип атады. Җитмәсә, фотолар алар чыгып китеп, берничә көн узгач кына барлыкка килде. Бу уңайдан Көнбатыш Мәскәүгә санкцияләрнең яңа өлешен өстәргә вәгъдә итә. Шул ук вакытта Вашингтоннан Мәскәү Киев белән килешүгә барса, санкцияләрнең алыну ихтималлыгына да ишарә итәләр.

Санкцияләр белән беррәттән Европа дәүләтләре ашкынып кораллануның яңа стадиясенә күчәләр. Америка Украинага авыр кораллар – танклар һәм һава һөҗүменә каршы торуның куәтлерәк системаларын бирүне анонслады. Мәскәүнең реакциясен көтәләр. Бу хакта җомга көнне New York Times газетасы хәбәрнең чыганагын яшереп игълан итте.

Германия үзенең Россия ракеталары алдында көчсез булуын аңлап пошаманга калды. Берлин ашыгыч рәвештә Израильнең яисә АКШның ракета һөҗүменә каршы тору системаларын сатып алу юнәлешендә эш башларга җыена. Бундесверның генераль инспекторы Эберхард Цорн: «Хәзергә бер генә нәрсә ачык: андый системаларны эшләү өчен безнең вакытыбыз да, акчабыз да юк», – дип белдерә. Немецлар Израильнең Arrow-3 ракетага каршы тору системасын яисә Американың мәшһүр THAAD комплексын үзләрендә булдырырга телиләр.

Төрекләр күптән түгел җитештерә башлаган HISAR O + уртача ераклыктагы һава һөҗүменә каршы тору системасын сатарга ниятләп рекламалый башладылар. Илнең тышкы эшләр министры Чавушуглы бу системаларның «Байрактар» һөҗүм итүче дроннары кебек үк уңышка ирешүләренә өметләнүләрен әйтте. Әнкара шулай ук үткән атнада 150 километр ераклыкка оча торган яңа «Çakır» канатлы ракетасын күрсәтте. Ракетаны коры җирдән дә, диңгез платформаларыннан да, очкычлардан да (шул исәптән дроннардан да) атып була. Проморолikта «Çakır» Россиянең зенит-ракета комплексын чәлпәрәмә китерә, белгечләр моңа шунда ук игътибар итте. Бундесвер вәкиленең: «Вакыт юк», – дигән сүзләре Көнбатышның ашыгыч рәвештә зур конфликтка әзерләнүенә ишарә итә. Тагын бер нәрсәне искәртик: үткән атнада Варшава АКШның атом-төш коралын үзендә урнаштыруга каршы булмавын белдерде.

Россиядә

АКЧАНЫ КУЯРГА УРЫН ТАБАСЫ БАР

Россия икътисадында кызыклы феномен пәйда булды: тышаулаучы санкцияләр нәтиҗәсендә илгә валюта яңгыры ява башлады. Углеводородлар дефициты фонында күккә күтәрелгән бәяләр шундый муллыкка китерде. Bloomberg агентлыгы: «Әгәр Россиянең энергоресурсларын төп сатып алучылар аларның импортына эмбарго игълан итмәсәләр, Россия 351 миллиард доллар эшләргә ихтимал. Бу рекордлы уңай сальдо булачак», – дип язды. Bloomberg әйтүенчә, илнең көтелә торган сәүдә һәм түләү балансы үткән елгы күрсәткечтән өчтән бер өлешкә югарырак булырга мөмкин. Әлегә вазгыять шундый: нефтьне һәм газны азрак саткан саен, акча күбрәк керә. Белгечләр чикләүче чараларның Россиягә валюта агымын туктата алмавын да искәртәләр. Бу санкцияләрнең тәэсирен йомшарта. Дөрес, Америка җитәкчелегендәге Көнбатыш коалициясе, нефть резервларын сатуга чыгарып һәм нефть җитештерүне арттырып, «кара алтын»га бәяне төшерергә омтыла, әмма тиз арада зур уңышка ирешелмәс, диләр.

Көн тәртибенә көтмәгәндә валюта янчыгына яуган акчаны ничек тоту мәсьәләсе килеп баса. Хәзер бит, теләсәң дә, капиталны чит илгә чыгарып булмый, ишекләр бикләнде. Эчке базарда исә паника нәтиҗәсендә бәяләр чамасыз күтәрелде. Пенсияләрнең һәм хезмәт хакларының реаль күләме бик нык кимеде. Иртәме-соңмы аларны индексацияләү көн тәртибенә баса. Вазгыятьнең парадоксы тагын шунда: валюта күп керүгә карамастан, предприятиеләр һәм бизнес кыенлыклар кичерә, хезмәт хакларын киметергә, эшчеләрне ялга җибәреп торырга туры килә. Пенсия фондына взнослар кими дигән сүз.

Пенсияләрнең реаль күләме кимүен Росстат та таный. Февральдә пенсионерлар үткән елның шул чоры белән чагыштырганда 1,8 процентка фәкыйрьләнделәр, ди. Бәяләр котырып үскән март күрсәткечләре әлегә исәпләнмәгән. Кыскасы, индексация инфляцияне куып тота алмый. Эшләүче пенсионерлар картлык акчасын бигрәк тә нык югалталар, аларныкы индексацияләнми бит. Дәүләт Думасы депутаты Оксана Дмитриева: «Без инженер пенсионерларны яңадан эшкә чакыру кирәклеге алдында торабыз», – ди. Хәзерге хәлдә аларның эшкә кайтасы килми, чөнки пенсия югалталар. Путинның федераль хөкүмәткә эшләүче пенсионерларның акчасын индексацияләргә әмер бирүенә шактый үтте инде. Тик боз эреми дә, урыныннан да селкенми. Йөз миллиардлаган бюджет долларлары чит илләрдә бикләнеп калды, индексация өчен хөкүмәт финанс чыганаклары таба алмады.

Бу юлы да илгә көтмәгәндә ява башлаган нефть долларлары файдаланып калынмаса, белгечләр дефициты нәтиҗәсендә импортны тагын кәгазьдә генә алыштырырга туры килмәгәе.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

tatarstan.ru

Көн саен 680 кеше кабул итә алалар. Казанның яңа бердәм туберкулез диспансерының мөмкинлекләре әнә шундый. Бинаның сырхауларны кабул итәргә әзерлеген Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та тикшерде.

Диспансер башкаланың Җиңү проспекты, 69Б адресы буенча урнашкан. Биредә балалар һәм флюорография бүлекләре, амбулатор эндоскопия, клиник-тикшерү лабораторияләре дә урнашачак.

Республика туберкулезга каршы клиник диспансерының баш табибы Алексей Алексеев сүзләренчә, диспансер көн саен 680 кешене кабул итә ала (шул исәптән, 260лап баланы). Бер тәүлек эчендә сырхауларга тулы диагностика үтәргә мөмкинлек булачак. Бу – белгечләрдән консультация алу, бактериологик һәм нурлы (лучевая) диагностика, клиник тикшерү.

Татарстан Президенты яңа бинаның эчен карап чыкты, хезмәткәрләр белән аралашты. Башкарган эшләргә республика җитәкчесе уңай бәя бирде. «Яхшы бина, җиһазлар да өр-яңа, заманча. Барысын да бер урында туплау дөрес булды», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Татарстан сәламәтлек саклау министры Марат Садыйков сүзләренчә, диспансерны якын арада ачарга җыеналар. Моның өчен барысы да әзер инде.

Бергә эшләгәндә җиңелрәк

Казанда Халыклар дуслыгы йортында Төрекмәнстан белән Россия Федерациясе арасында дипломатик мөнәсәбәтләр урнаштырылуга 30 ел тулуга багышланган фәнни-мәдәни чара узды. Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан халыклары ассамблеясы советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин юллаган котлауны парламент депутаты Римма Ратникова җиткерде.

«Төрекмәнстан белән Татарстанның тугандаш халыклары арасындагы дустанә мөнәсәбәтләр елдан-ел ныгый. Рөстәм Миңнеханов һәм Горбангулы Бәрдымөхәммәдовның әлеге элемтәләргә даими игътибары төрле яклы хезмәттәшлекнең алга таба тагын да ныгыячагына ышаныч тудыра», – диелә котлауда.

Фәрит Мөхәммәтшин үзенең котлавында билгеләп үткәнчә, вакытлар белән сыналган мөнәсәбәтләрне үстерүдә Төрекмәнстанның Казандагы Генераль консуллыгы һәм Татарстанның Төрекмәнстандагы Вәкаләтле вәкиллеге зур өлеш кертә. «Бүгенге чараның Татарстан халыклары дуслыгы йортында – Халыклар ассамблеясының төп үзәгендә узуы зур мәгънәгә ия. Төрекмәннәрнең Татарстандагы җәмгыяте, татарларның Төрекмәнстандагы җәмгыяте дустанә мөнәсәбәтләрне үстерүгә зур өлеш кертә, дуслыкны ныгыта. Барлык юнәлешләр буенча ике як өчен дә файдалы хезмәттәшлек тәҗрибәсе тупланды, дәүләтләребезнең сәүдә-икътисади, фәнни-техник, гуманитар элемтәләре ныгый», – диелә Татарстан халыклары ассамблеясы советы рәисе котлавында.

Фәрит Мөхәммәтшин тупланган хезмәттәшлек тәҗрибәсенең алга таба да Татарстан белән Төрекмәнстан халыклары арасындагы тугандаш элемтәләрне киңәйтү һәм ныгытуга юнәлдереләчәгенә ышаныч белдерә. «Төрекмәнстандагы дусларыбызны дипломатик мөнәсәбәтләр булдырылуга 30 ел тулу, шулай ук Изге рамазан ае башлану уңаеннан эчкерсез кайнар котлыйм!» Барлык башлангычларыгызда уңышлар телим!» – диелә котлауда.

Төрекмәнстанның Казандагы Генераль консулы Атадурды Бәйрәмов әйтүенчә, алар алга таба да мөнәсәбәтләрне үстерүгә өметләнә.

«Кайтыр идем, өем юк...»

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

«Өем дә юк, шәһәрем дә...»

Ят шәһәргә аяк баскан кешеләрнең, әлбәттә, журналистлар белән ачылып сөйләшергә теләкләре зурдан түгел иде. Кайсылары йөзен яшерде, кул гына болгады. Ару-талчыгу да, поездның башкалага төнге сәгатьләрдә кайтуы да тәэсир иткәндер инде. Шактые утка тотылган Мариупольдән булып чыкты. Шулай да күпчелеге беравыздан бары бер сүзне кабатлый: «Рәхмәт!» Поездда аларны бар нәрсә белән дә тәэмин иткәннәр. Республиканың кунакчыллыгын ишетеп кенә түгел, гамәлдә дә күрдек, диде кайсылары. Моңа кадәр Татарстан һәм аның башкаласы турында интернет һәм китаплардан укып кына хәбәрдар булганнар икән.

Артур Кириллов Казанга гаиләсе белән кайткан. Россиягә эләгү өчен шактый кыен ашарга туры килә әле аларга. 30 чакрым җәяү дә үтәләр, аннан гына махсус пунктта волонтерлар ярдәме белән күченеп китәргә мөмкинлек табалар. Артур туган ягына кайтырга җыенмый. Дөресрәге, моңа өмете юк. «Кайтырга? Анда бит шәһәр юк инде...» – ди ул.

Александр Матура – Мариупольдән. Ул да Казанда калырга җыена.

– Кайтыр өчен шәһәр кирәк, ә ул юк, димәк, кайтыр җирем дә юк. Казанда калырга уйлыйм. Алга таба нишләргә җыенаммы? Яшәргә һәм эшләргә, – ди бер чемодан белән Татарстанга күченеп кайткан әңгәмәдәшебез.

Олы яшьтәге Петр исемле абзый Казанга берүзе генә кайткан. Улы Донецк армиясе составында хезмәт итә икән, кызганыч, тормыш иптәше күптән вафат. Моңа кадәр Горловка бистәсеннән ерак булмаган шәһәрдә яшәгән.

– Хәзер минем өем дә, бернәрсәм дә юк. Әнә бер букчам, бар байлыгым – шул. Туган җирдә нинди вазгыятьтер – белмим, – дип сүзен кыска тотты ул.

Мариупольдә яшәгән Анжела ханым шәһәрдәге атышлар турында борчусыз гына сөйли алмый. Зинаида Михайленко да – шул шәһәрдән. «Үзлектән эвакуацияләнә башлаган идек. Берничә чакрым җәяү бардык. Безнең монда беркемебез дә юк. Минем кызым, киявем һәм оныгым бар иде. Алар белән бер ай элемтәгә кергән юк инде. Юлларыбыз шул рәвешле аерылды. Татарстанда мөмкин булганча озаграк калырга уйлыйбыз», – диде ул.

– Алга таба нәрсә эшлисен белмибез әле. Иң мөһиме – урнашу, ял итеп алу. Туган якта әти-әнием калды, әмма аларга куркыныч янамый, – диде Мариупольдән Наталья Голодова. – Юл бик озын булды. Өч тәүлек килдек. Әмма кыенлыклар булмады. Оештыру югары дәрәҗәдә иде. Ашаттылар-эчерттеләр. Безне ташлап калдырмаслар, биредә шартлар тудырырга вәгъдә иттеләр. Татарстан турында моңа кадәр беркайчан да ишеткәнем булмады. Әлегә туган якка кире кайту теләге юк. Дөресен әйткәндә, яшәү өчен шартлар да калмады инде анда. Ут, газ юк, барысы да бомбага тотылды, анда безне үтерәләр.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Казан волонтерлары кыен хәлдә калганнар өчен кием-салым кабул итү пунктын оештырып җибәрде. Волонтер Юлия Хәкимова әйтүенчә, күченеп кайтучыларның күпчелегенең бер нәрсәсе дә юк. «Битараф булмаган кешеләр пунктка бүген үк мөрәҗәгать итә башлады. Мәктәп балалары, олылар күпләп әйберләр алып килә. Әмма ярдәм һаман да кирәк. Күпчелек балаларга өскә кияргә һәм аяк киеме җитми. Спорт киеме, футболка, халат ише кием-салым да кирәк. Нәниләр исә гигиена кирәк-яракларына, балалар ризыгына мохтаҗ», – диде ул.

Пунктның адресы: 2 нче Көньяк-Көнбатыш урамы, 30.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

ФЕРМЕР ГӨЛНАЗ ЩУКИНА:

«ХАЛЫК ХИМИЯ АШАП ТУЙДЫ»

Татарстанныкын сайла

Кайбыч районының Чүти авылында яшәүче фермер Гөлназ Щукина әйтүенчә, азык-төлек базарындагы бүгенге вазгыять – Татарстан фермерларының продукцияләрен тәкъдим итәр өчен яхшы мөмкинлек.

– Халык химия ашап туйды. Алар хәзер табигыйлеккә өстенлек бирә, – дип фикер йөртә эшмәкәр. – Шуңа күрә яхшы, сыйфатлы продукциягә ихтыяҗ һәрвакыт булачак. Ә туган җирдә үстерелгән һәр нәрсә табигый, чиста һәм һичшиксез тәмле. Мин ит продуктларын чит илдән кертелә башлаган вакытларны хәтерлим. Һәм шул вакытларда: «Без үз илебездә дә сыйфатлы ярымфабрикатлар, казылыклар ясап, аларны матур төргәкләргә төреп сата алабыз бит», – дип уйлый идем. Бүген безнең кебек урта кул эшмәкәрләргә үз-үзләрен күрсәтер һәм сыйфатлы продукция җитештерү буенча эшчәнлекне киңәйтергә мөмкинлекләр ачылды.

Гөлназ ханым – фермерлар династиясеннән. Әти-әнисе дә, абыйсы да гомер буе авылда, терлек арасында җиң сызганып эшләүчеләр. Бүген дә эшләрен бергәләп алып баралар. Моңа кадәр бухгалтер булып эшләгән Гөлназ Щукинага өч ел элек «Йолдыз» кооперативында технолог һөнәрен үзләштерә башларга туры килгән.

– Әти-әнигә ярдәм кирәк булгач, гаиләм белән Казаннан күченеп кайттык, – дип искә ала ул вакытларны эшмәкәр. – Башта авылда сәркатип булып эшләдем. Кооператив буларак берләшкәч, технолог булырга туры килде. Баштагы вакытларда авырлыклар да булды. Иң авыры итне ысларга өйрәнү иде. Килеп чыкканчы шактый тырышырга туры килде. Киңәш сорарга да кеше юк, чөнки якын-тирәдә без – беренче. Эшли-эшли шомарырга, сатып алучыларның фикерләрен, теләк-тәкъдимнәрен белешеп, камилләшергә туры килде. Киләчәктә кооперативларга кешеләрне шундый һөнәрләргә укыту мөмкинлеге дә барлыкка килсен иде.

Узган ел исә ул «Россельхозбанк»ның «Фермерлар мәктәбе» проектында катнашып, 4 миллион сумга якын грант отып, үз фермасын ачкан. Беренче эш итеп 50 үгез һәм ит ташыр өчен машина сатып алганнар.

– Бу ферманы ачу хыялы сыйфатлы продукция җитештерергә теләгәнлектән барлыкка килде. Кооператив әгъзаларында эшкәртү өчен ит бетеп киткән вакытларда аны башкалардан да сатып алгаладык. Ләкин читтән алган иттән казылык ясап булмаган очраклар да еш булды. Чөнки антибиотиклар, төрле кушылмалар ашап үскән малның итеннән казылык ясап булмый. Яки маллар ябык була торган иде. Гомумән, тәҗрибәле кешеләр сыйфатсыз итне шунда ук аера ала.

Гөлназ ханым бүген дә технолог эшен ташламаган. Сүз уңаеннан, «Йолдыз» кооперативы эшчәнлекләрендә яхшы күрсәткечләргә ирешү белән беррәттән, пайчылар саны буенча да республикада иң эре кооперативлардан санала. Аңа 300гә якын пайчы берләшкән. Үзләренең мал чалу цехлары бар.

– Цехка башка терлекләрне кертмибез, чөнки без хәләл стандартлар буенча эшлибез, – ди Гөлназ Щукина.

Кооперативта колбаса, кош һәм ат, сарык ите ыслыйлар, пилмән, кәтлит, мантый, тулма (голубцы), берничә төрле тутырма, шашлык һәм башка ярымфабрикатлар ясыйлар. Көзен казларны да шушында ыслап та, түшкәсе белән дә саталар. Халык аеруча кулдан бөккән пилмән, кәтлитне, ысланган итне яратып ала икән. Иң мөһиме – ризыкларның барысы да хәләл. Колбасаны 80 процент – ат, 20 процентын тана итеннән ясыйлар. Җитештерелгән продукцияне Апас, Кайбыч кибетләрендә саталар. Тәмле һәм хәләл ризыкларны Казан белән Чувашия Республикасына да алып китәләр. Моннан тыш, авыл хуҗалыгы ярминкәләрендә дә еш катнаша алар. Аның сүзләренә караганда, моңа кадәр итнең бер килограммын 390–400 сумнан сатканнар. Чыгарылган итне исә 450 сумга тәкъдим иткән булганнар. Тик бу айдан ит бәяләрен бераз күтәрергә планлаштырып торалар.

– Беренче елларда сату авырдан барды, чөнки халык алдында ышаныч казанырга кирәк иде. Өч ел дәвамында халыкның нәрсәне ныграк яратуын өйрәндек. Безнең халыкка олы мал ите булсын. Аларның тавыкка исе китми. Безнең итнең һәм җитештергән продукциянең сыйфатлы булуына инанган кешеләр күп хәзер. Өч ел буена бездән генә сатып алучы клиентларыбыз бар. Яңалык булара к, абыем сарделька ясый башлады, чөнки минем моңа аппаратым юк. Үгезләр өчен дә ул җаваплы, ышанычлы уң кулым. Ә апа белән җизни продукцияне Казан ярминкәсендә сата. Кыскасы, бөтен гаиләбез белән авыл хуҗалыгы өчен тырышабыз, – ди Гөлназ Щукина.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ДӨНЬЯ МӨСЕЛМАННАРЫН БЕРЛӘШТЕРҮ БӘЙРӘМЕ

Иманлы юл

Без Ватан тарихының гаять әһәмиятле чорына килеп кердек: быел Идел буе Болгарстанында рәсми рәвештә ислам дине кабул ителүгә 1100 ел була. Изге Болгар шәһәрендә 922 елда булып узган вакыйга ул чорда дәүләтебезнең дипломатик яктан танылуына китерсә, бүгенге татар халкының һәм Россиядәге һәммә мөселман өммәтенең рухи-мәдәни үсеш юлларын билгели. Әйтергә кирәк, мондый олы бәйрәмне үткәрү өчен әзерлек эшләре күптән башланды инде.

Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары Илфар хәзрәт ХӘСӘНОВ белән без шул хакта сөйләшәбез.

– Юбилейны үткәрү тәкъдимен инде 2016 елда ук Россия мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти шәех Равил Гайнетдин күтәреп чыккан иде. 2020 елның 4 ноябрендә Владимир Путин Халыклар бердәмлеге көне уңаеннан дин эшлеклеләре белән очрашуда юбилей чараларын дәүләт дәрәҗәсендә үткәрүне хуплады. 2021 елның 28 апрелендә бәйрәм уздыру турында боерыкка кул куйды. Шуның белән бергә федераль оештыру комитеты да расланды. Үзәкләштерелгән дини оешмалар җитәкчеләрен, җәмәгать һәм дәүләт эшлеклеләрен, галимнәрне берләштергән әлеге комитетның рәисе итеп Россия Хөкүмәте Рәисе урынбасары Марат Хөснуллин билгеләнде.

:: Белүебезчә, Татарстан эшне озакка суздырмады кебек...

– Республикабызның оештыру комитетын Рөстәм Миңнеханов җитәкли. Россия Президенты боерыкка кул куйганнан соң, чыннан да, эшләр күз иярмәслек тизлек белән башланды. Инде 5 июньдә үк «Изге Болгар җыены»нда киңәшмә үткәрелде. Анда федераль план проектына кертү өчен дин әһелләре, галимнәр үз тәкъдимнәрен җиткерделәр.

:: Федераль план 71 пунктны үз эченә ала. Ислам дөньясына аеруча саллы яңалыклар алып килүче төп чараларның берничәсе белән укучыларыбызны да таныштырып китик әле.

– Әлеге исемлеккә Казанда Җәмигъ мәчетенә, Түбән Новгородта тарихи Ярминкә мәчетенә нигез ташы салу, Уфадагы Россия Ислам университетының яңа комплексын, Сембердә Болгар чорына караган тарихи-мәдәни комплексны ачу эшләре кергән. Казандагы тарихи «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен яңарту эшләрен тәмамлау да күздә тотыла. Инде бәйрәмгә планетабызның төрле почмакларыннан кунаклар киләсе булгач, йортҗиребезне дә карап куярга кирәк. Бу җәһәттән Болгарга килү юллары һәм урам-юл челтәре объектлары ремонтлана. Мәдәният өлкәсендә дә эшлисе эшләребез күп. Россия халыкларының милли әдәбият фестивален үткәрергә җыенабыз. Болгар чорына караган язма ядкәрләрне барлап, китап итеп бастыру эшләре дә бара. Бу җәһәттән инкыйлабка кадәрге татар дин галимнәре хезмәтләре дә читтә калмый. «Россия Федерациясендә – ислам» дип аталган 8 томлык энциклопедик сүзлек тә дөнья күрәчәк. Россия ислам институты тарафыннан әзерләнгән «Россиядә ислам тарихы» дигән китап инглиз, гарәп телләренә тәрҗемә ителә.

dumrt.ru

:: Республика дәрәҗәсендә эшләнә торган чаралар да байтак булырга охшаган.

– Әлбәттә. Болгарның үзеннән башласак, шәһәргә керү юлларында стелалар куела, кунаклар өчен чатыр лагере үзгәртеп корыла. «Болгар цивилизациясе музее» экспозициясен яңарту эшләре бара. Башкалабыз да читтә калмый. Казанда «Болгар» мәчетенең фасады ремонтлана. Болгар илендә исламның таралышы, аның нигезләре, мөселман мәгърифәте һәм мәдәнияте турында лекцияләр уздырыла. Халыкара һәм Россиякүләм конференцияләр әзерләнә. Театрларда спектакльләр куела, фильмнар төшерелә, видеороликлар эшләнә. Басма һәм сувенир продукция җитештерелә. Күргәзмәләр һәм бәйгеләр үткәрелә…

:: Бу изге эштә республикабыз районнары да читтә калмый дип уйларга кирәк?

– Муниципаль берәмлекләр дә бик актив кушылды. Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте белән берлектә, мөхтәсибәт, дини белем бирү оешмалары һәм иҗтимагый берләшмәләрне дә җәлеп итеп, бу юнәлештә җирле хакимиятләр дәрәҗәсендә саллы эшгамәлләр башкарыла.

:: Татарстан Президенты бәйрәм уңаеннан үткәрелгән форумда Казанны «Беренче басма Коръән шәһәре» дип атау тәкъдиме белән чыккан иде...

– Бу чыннан да шулай. 1803 елда Казанда мөселманнар тарафыннан төзелгән беренче Коръән китабы дөнья күрә. Ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгы кысасында бу җәһәттән тагын бер проект башланды. Шиһабетдин Мәрҗани, Муса Бигиевнең хезмәтләренә нигезләнеп, каллиграфларны җәлеп итеп, Коръән матур итеп кулдан языла башлады.

«Ислам кабул итүнең 1100 еллыгы» логотибы проектын Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе урынбасары, «Хозур» нәшрият йорты директоры Ришат Хәмидуллин тәкъдим итте. Татарстан Президенты бу хакта: «Федераль оештыру комитетына кертергә, хуплау алырга кирәк, бу тирән, нигезле эш дип саныйм», – дип үз фикерен җиткерде.

Логотип 5 график элементтан тора:
Болгардагы Хәтер билгесе, ачык Коръән китабы, лалә чәчәге, рус һәм гарәп телләрендә язу кагыйдәләрен кулланып, «1100» язмасы, Болгар сүзенең гарәп телендә язылышы.

:: Бәйрәм уңаеннан милли көрәш бәйгесе үткәрү дә карала. Ни өчен нәкъ менә спортның әлеге төре?

– Бу җәһәттән Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин «Россия Көрәш федерациясе» вице-президенты белән гыйнвар аенда ук күрешеп сөйләшкән иде инде. Анда сүз бәйрәм кысасында татар милли көрәше буенча Россиякүләм һәм дөньякүләм турнирлар оештыру турында сүз барды. Ни өчен дигән сорауга җавап мондый: спортның бу төре Гарәбстан сәяхәтчесе Ибн Фадлан елъязмаларында телгә алына, татар дин әһелләре үзләре дә көрәшчеләр, баһадир гәүдәле, көчле, батыр кешеләр булганнар. Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгы кубогына Чаллыда татар милли көрәше һәм кул көрәше буенча Берләштерелгән Россиякүләм турнир узды. Үз үлчәү категориясендә җиңү яулаган егетләр арасында жирәбә ярдәмендә хаҗга юллама уйнатылды. Әлеге зур бүләкне Татарстан мөфтияте бирде. Дөнья кубогына көрәш Болгарда бәйрәм көнне – 21 майда үтәр дип көтелә.

Иң мөһиме шунда: бу бәйрәм Россиядә генә түгел, бөтен дөньяда яшәүче мөселманнарны берләштерергә тиеш. Һәр чара нәкъ менә шушы бурычны күздә тотып үткәрелә.

Әңгәмәдәш – Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

▶ 922 елда гарәп илчеләре Болгар каласына килә. Бу вакытта хан булып Шилке улы Алмыш тора. Ул Багдад хәлифенә ислам динен белүче кешеләрне җибәрүен, шулай ук мәчет һәм кирмән төзүдә ярдәм итүләрен сорап хат яза. Бу хакта илчелекнең сәркатибе Ибн Фадлан сәяхәтнамәсендә язып калдыра. Шуңа нигезләнеп, Идел буенда ислам динен рәсми кабул итү елы булып 922 ел санала да инде. Ибн Фадлан юльязмасында Болгарда азан әйтелүе, мәчетнең төзәтелүе турында телгә ала. Тарих битләреннән күренгәнчә, X гасыр башында ук Алмыш хан тәңкәләрендә аның гарәпчә исеме (Җәгъфәр бин Габдуллаһ) басылган. Ягъни бу ата-бабаларыбыз әлеге вакыйгаларга кадәр үк ислам дине белән таныш булган, аны үз ирege белән кабул иткән дигәнне аңлата.

Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясенә кандидатлар

МИЛЛИ ҖАНЛЫ АРХИТЕКТОР

Беркем дә дөньяга мәңгелеккә килми. Шуны аңлап, кеше Аллаһ тарафыннан үзенә бүләк ителгән гомерне бәрәкәтле итәргә тырыша. Галимнәр яңа ачышларга омтыла, табиблар кеше гомере сагында тора. Һәркем үз юнәлешендә осталыкка, камиллеккә ирешергә тырыша. Минем язмамның герое да шундый.

Фирдәвис Ханов. Бу исемне Түбән Кама шәһәре һәм районында яшәүчеләр белми калмас дисәм, нарасыйлар искәрмә булырга мөмкин. Өлкән һәм урта буын арасында гына түгел, яшьләр даирәсендә дә популяр бу шәхес. Чөнки ул «күп». Ул өлгер. Аны һәр милли чарада күрергә мөмкин. Һәм һәркайда да бәйрәмнең яме, төпле фикерен җиткерә белүче кадерле кунак. Ялындырып тормас, җырлап та җибәрер, кирәк урында иплән кенә «чеметеп» тә алыр, ләкин берәүне дә кыерсытмас, йөрәген җәрәхәтләмәс җор телле, Түбән Каманың чын асыл ире, милләтпәрвәре. Ниһаять, даны республика һәм Россия чикләрен үтеп чыккан архитектор. Шушы өлкәдә күп бәйгеләрдә төрле дәрәҗәдәге җиңүләргә ирешкән, теләге булса, читкә китеп, югары пост били алган, әмма бөтен барлыгы белән Ватанына әйләнгән Түбән Камага береккән, исемен баш хәреф белән язарлык Архитектор ул – Фирдәвис Ханов.

Артык мактый димәгез, чынбарлыгы шундый. Мин моны героемны күп еллар белгәнгә, дәлилләрлегем булганга шулай язам. Аның кандидатурасын ике тапкыр Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясенә тәкъдим иттеләр, тик үтмәде. Сөмсере коелмады, киресенчә, тагын да дәртләнебрәк эшли башлады кебек. Түбән Кама шәһәренең 55 еллыгына туры китереп, тормыш юлы, хезмәтләренең фотолары тупланмасын нәшер итте. Аннан 1978 елдан, ягъни Түбән Камада яши башлаган тәүге көненнән башлап, бүгенгә кадәр иҗат иткән хезмәтләрен чагылдырган фотолар күргәзмәсе оештырды. Бер ай дәвамында халык шәһәр музеена юлны суытмады. Гид ролен, күпчелек очракта, Фирдәвис әфәнде үзе башкарды.

– Менә монысы – сез эшләгән ЗАГС бинасы. Аны төзүнең үз тарихы бар. Чынлыкта, ул башка урында булырга тиеш иде. Ә бу бина бөтенләй, бүтән оешма өчен ниятләнде, – ди ул ЗАГС хезмәткәрләрен үз күргәзмәсе белән таныштырганда. Аннан дәвам итә: – Бина-корылмаларның да язмышы кешенеке кебек алдан билгеләп куела димме… Минем хезмәт юлында көтелмәгән кискен борылышлар, ачы язмышка дучар ителгән архитектура объектлары булгалады. Тик мин һәр очракның үзенә күрә бер уңай ягын күрергә, аны эләктереп алып, секунды белән башка тарафта кулланырга тырыша идем. Шуңа да күп кенә идеяләремне озак вакытлар күңелемнең иң түрендә сакларга туры килде.

Шундый кадерле проектларының берсе – Габдулла Тукай исемендәге уку һәм ял паркы. Билгесезлектә уздырган йокысыз төннәр нәтиҗәсе булган әлеге проектны тормышка ашыру җиңел бирелми аңа. Тагын да төгәлрәк әйтсәк, көрәшергә туры килә. Ярый әле республикада Парк һәм скверлар елы игълан ителеп, «Рөхсәт ителми» мөһере сугылган проект алдында «яшел ут» кабына.

– Тукай паркының язмышы катлаулы. Аны төзи башлау, төзү, тантаналы рәвештә ачу шатлыгын чагылдыра торган сүзләр юк. Минем өчен гомеремдә бер тапкыр гына кичерә торган халәт булды ул. Түбән Камада татарларның горурлыгы, яраткан шагыйренә тулы бер һәйкәл комплексы барлыкка килде бит! Тукаебызны әнә шул рәвешле танытырга теләдем. Паркта аның берничә герое «яши». Биредә шагыйрьнең ике телдә шигырьләре яңгырый. Мактана, кәпрәя дисеннәр, әмма хаклыктан китеп булмый: исеменә җисеме туры килгән парк бу! Ә андыйлар бик сирәк, – ди архитектор.

Менә шушы паркы өчен, аның төзелешен күп еллар сабыр гына көтәргә тәкате җитүе өчен дә лаек ул Тукай премиясенә. Юк, бу гына аз диючеләргә аның кырык елдан артык тудырган иҗат җимешләре исемлеген тәкъдим итә алам. Ләкин нигә? Ул – үз вакытында шәһәрнең шырпы кабын хәтерләткән күпкатлы йортлары фасадларына милли бизәкләр кертергә җөрьәт иткән кыю йөрәкле архитектор. Дөрес, ул бизәкләрне күрә белергә кирәк, тик бер калып буенча эшләү, милли рух турында авыз ачарга тыелган еллар өчен бу зур батырлык иде.

– Аларның эскизларын ясап кына калмыйча, заводта эш процессын үзем контрольдә тоттым. Үзәк мәчет каршындагы тугыз катлы йорт, мәсәлән, мәчет темасын тулыландырып торырга тиеш иде. Тик, ни кызганыч, идеянең бер өлеше генә тормышка ашырылды. Бүген аны йортның кәрнизле этажында күрергә була. Шулай да ул шәһәргә ямь биреп тора дип саныйм, – ди ул.

Фирдәвис Ханов турында иҗат итүче түрә дип яздылар. Моның белән килешми мөмкин түгел. Ул – Россиянең һәм Татарстанның атказанган архитекторы, Түбән Кама шәһәренең мактаулы гражданины, РФ архитекторлар шурасының «Алтын Кентавр» билгесе, «Россиянең иң яхшы архитекторы» исеме иясе. Шулай да аның хезмәтләренә иң югары бәя – халык сүзе. Ә түбәнкамалылар аның һәр эшен яратып кабул итә. Ул бәя тагын да югары булыр иде, әгәр кайбер объектларның архитекторы Фирдәвис Ханов икәнен белсәләр. Туып кына килә торган проектлары, «их, шулай булса иде!» дигән татлы хыялларга төренгән эшләре дә бар аның. Аларның барысында да милли рух сизелә, милли аһәң яңгырый. Һәрхәлдә, архитекторның эскизларында бу шулай…

Ул инде күптән лаеклы ялда. Ләкин ул һаман хәрәкәттә. Бүгенгесе белән канәгать булып, киләчәккә планнар корып яши.

Яше җитмеш чиген атлап чыкса да, заманча фикерле, проектларын бүгенге буын яшьләре күзлеге аша карап «тудыра», хезмәтләре рецептына хыялларын да өстәп иҗат итә белүче милләтпәрвәр якташыбызга уңышлар теләп,

Нурисә ГАБДУЛЛИНА.
Түбән Кама

Рәсми документ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы һәм Украина территорияләрендә уздырыла торган махсус хәрби операциядә катнашулары нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләре хәрби хезмәткәрләренең һәм аларда хезмәт иткән затларның гаилә әгъзаларына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында

2022 елның 24 февраленнән Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы һәм Украина территорияләрендә уздырыла торган махсус хәрби операциядә катнашулары нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләре хәрби хезмәткәрләренең һәм аларда хезмәт иткән затларның гаилә әгъзаларына матди ярдәм күрсәтү максатларында **карар бирәм:**

1. 2022 елның 24 февраленнән Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы һәм Украина территорияләрендә уздырыла торган махсус хәрби операциядә катнашулары нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләре хәрби хезмәткәрләренең һәм аларда хезмәт иткән һәм махсус полиция званиесе булган затларның (алга таба – хәрби хезмәткәрләр) гаилә әгъзаларына 2 млн сум күләмендә, әлеге Указның 2 пунктында күрсәтелгән һәр затка бертигез өлештә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү (алга таба – бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү) билгеләргә.

2. Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү түбәндәгеләргә бирелә дип билгеләргә:

хәрби хезмәткәрнең һәлак булган (вафат булган) көненә аның белән теркәлгән никахта торган хатынына (иренә);

хәрби хезмәткәрнең әти-әнисенә (аны уллыкка яки кызлыкка алучыларга);

хәрби хезмәткәргә карата ул балигълык чорына җиткәнче кимендә биш ел дәвамында опекунлык (попечительлек) вазыйфаларын үтәгән затларга;

хәрби хезмәткәрнең балаларына.

3. Әлеге Указны үтәү максатларын күздә тотып, һәлак булган (вафат булган) хәрби хезмәткәрләргә туган яисә яшәгән урыны Татарстан Республикасы территориясендә булган яки Татарстан Республикасы территориясендә җирләнгән гражданнар кертелә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне башкару тәртибен расларга;

әлеге Указны үтәү белән бәйле чыгымнарны финанслауны билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә, шулай ук аны гамәлгә ашыру буенча башка карарлар кабул итәргә.

5. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов
Казан, Кремль, 2022 ел, 4 апрель
№ ПУ-233

Белдерү

Кадастровым инженером Кутдусовой Натальей Генадьевной (СНИЛС № 128-830-216 57), являющейся членом СРО АКИ «Поволжье» (номер в реестре СРО 0182, дата вступления 05.07.2013 г., квалификационный аттестат № 16-11-417, адрес: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Салиха Батыева, д. 1, адрес электронной почты: m2405085@yandex.ru, тел.: 8(843)2405085), в отношении земельного участка с кадастровым номером 16:50:270251:58, расположенного по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, Советский район, п. Вознесенское, ул. Луговая, д. 44, выполняются кадастровые работы по уточнению границ и площади земельного участка.

Заказчиком кадастровых работ является Карсакова О.Н. (тел.: 8-9047626995). Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования границ состоится по адресу: 420129, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Салиха Батыева, д. 1 6 мая 2022 г. в 10.30 минут. С проектом межевого плана земельного участка можно ознакомиться по адресу: 420129, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Салиха Батыева, д. 1. Обоснованные возражения относительно местоположения границ, содержащихся в проекте межевого плана и требования о проведении согласования местоположения границ земельных участков на местности принимаются ежедневно с 9 до 17 часов с 11 апреля 2022 г. до 6 мая 2022 г. по адресу: 420129, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Салиха Батыева, д. 1.

Смежный земельный участок с правообладателем, которого требуется согласовать местоположение границ – 16:50:270251:92, расположенный по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, Советский район, п. Вознесенское, ул. Луговая, д. 46.

При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы, подтверждающие права на соответствующий земельный участок.

Кадастровым инженером Кутдусовой Натальей Генадьевной (СНИЛС № 128-830-216 57), являющейся членом СРО АКИ «Поволжье» (номер в реестре СРО: 0182, дата вступления 05.07.2013 г., квалификационный аттестат № 16-11-417, адрес: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Салиха Батыева, д. 1, адрес электронной почты: m2405085@yandex.ru, тел.: 8(843)2405085), подготовлен проект межевания земельных участков, выделяемых в счет земельных долей из земельного участка с кадастровым номером 16:16:000000:7224, расположенных по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, Советский район, в границах АФ «Нокса».

Заказчиком кадастровых работ является Федулов Е.В. (тел.: 89655986986). Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования границ состоится по адресу: 420129, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Салиха Батыева, д. 1 11 мая 2022 г. в 10.30 час. С проектом межевания земельных участков можно ознакомиться по адресу: 420129, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Салиха Батыева, д. 1. Обоснованные возражения относительно местоположения границ, содержащихся в проекте межевания и требования о проведении согласования местоположения границ земельных участков на местности принимаются ежедневно с 9 до 17 часов с 11 апреля 2022 г. до 11 мая 2022 г. по адресу: 420129, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Салиха Батыева, д. 1.

При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы, подтверждающие права на соответствующий земельный участок.

Спорт

rubin-kazan.ru

Үзебез генә калдык

«Әйе, имән кебек 300 ел яшәргә һәм гомерем буе эшләргә әзер мин». «Рубин» соңгы урында баручы «Химки»га оттыргач, баш тренер Леонид Слуцкий үзенең киләчәге турындагы сорауга әнә шулай дип җавап бирде. 2019 елда аны Казан командасын премьер-лигада калдыру өчен чакырганнар иде. Инде менә кабат шул куркыныч яный.

20 март көнне «Рубин» Мәскәүдә 1:6 исәбе белән ЦСКАга оттыргач, Леонид Слуцкийның үз вазыйфасыннан китәргә мәҗбүр буласын фаразлаучылар да табылды. Казан клубының генераль директоры Рөстәм Сайманов исә остазны яклап чыкты. «Без аңа тулысынча ышанабыз. Сезон ахыры гына түгел, ул бездә гомерлеккә калачак», – диде Сайманов. Ике атналык тәнәфес вакытында команда бераз хәл алыр, тынычланыр, баш тренер да уйларын тәртипкә китерер дип фаразладылар. Әмма алай булып чыкмады.

Әле ЦСКАга каршы узган матчка кадәр үк Филип Уремович, Сеад Хакшабанович һәм Андрес Дрейер «Рубин» белән килешүләрен туктатып торырга карар кылды. ФИФА Россиядә чыгыш ясаучы чит ил уенчыларына әнә шундый мөмкинлек бирә. Өчесе дә – команданың төп уенчылары. Әмма иң авыры алдарак булган икән. ЦСКА белән булган матчтан соң Хвича Кварацхелия дә Грузиягә кайтып китте. Башкалар кебек булыр, җәй көне кабат Казанга килер дип өметләнделәр. Ә соңрак футболчының «Рубин» белән араны тулысынча өзүе ачыкланды. 21 яшьлек уенчы Батуми «Динамо»сы белән килешү төзегән. Грузин егетен зур акчага сатып, финанс хәлен яхшырту турында хыялланган клуб кына түгел, баш тренерның шәхсән үзе өчен дә зур югалту булды әлеге вакыйга. Ник дигәндә, әле Казанга килгәч үк Леонид Слуцкий Хвича кебек уенчылар белән эшләүнең үзе өчен үтә дә мөһим икәнен әйткән иде. Хәзер исә акча да, футболчы да юк.

Гомумән алганда, «Рубин»нан иң мөһим уенчылардан саналган 6 футболчы китте. Казан командасы составында чит илдән нибары ике уенчы – Тунис егете Монтассар Тальби һәм Даниядән Оливер Абильгор гына бар. Шулай итеп, калганнардан яңа команда корырга туры килә. Беренче уенда килеп чыкмады. Якташларыбыз үз кырында «Химки»га оттырды. Казан сакчылары премьер-лигада соңгы урында барган команда һөҗүмчеләренә каршы берни майтара алмады. Ә җиңелүгә китергән өченче тупны «Рубин» матчның соңгы минутында керттерде. Монысы – команданың рухы ни дәрәҗәдә нык булуын раслый торган дәлил.

Бу – башкала командасының рәттән өченче җиңелүе. Хәзер безнекеләр 25 очко белән турнир таблицасында 11 нче урында урнашты. Соңгы дүрт урындагы «Урал», «Химки», «Арсенал» һәм «Уфа»ның 21әр очкосы бар. Алдагы матчлар күңелле тормыш вәгъдә итми. Казан командасын башта «Краснодар» һәм «Спартак»ка каршы очрашулар көтә. Сезон ахырында исә премьер-лигада калу өчен көрәшүче «Арсенал», «Урал» һәм «Уфа»га каршы уйныйсы. Леонид Слуцкийны 2019 елның декабрендә батып баручы «Рубин»ны коткару өчен чакырганнар иде. Ул үз бурычын үтәде һәм Казан командасы премьер-лигада калды. Бу юлы хәлләр мөшкелрәк булырга мөмкин.

	команда	очко
1	Зенит	49
2	Динамо М	46
3	ЦСКА	43
4	Сочи	39
5	Локомотив	37
6	Краснодар	36
7	Ахмат	32
8	Кр. Советов	32
9	Н. Новгород	27
10	Спартак	27
11	**Рубин**	**25**
12	Ростов	22
13	Арсенал Тула	21
14	Химки	21
15	Урал	21
16	Уфа	21


«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА
РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

АЛТЫН ТАУДА – ӘЛИФБА

Без тарихта эзлебез

Зәңгәр тышлы Әлифбаны хәтерлисезме икән? Тышлык рәсемендә букча тоткан ак алъяпкычлы кыз мәктәпкә бара, янәшәсеннән көчек йөгерә. Бер караганда, инде тарих битләренә кереп калган күренеш кебек. Әмма бүген дәреслекнең авторы Сәләй ага Вәгыйзовның (ул аны хәләле Рәмзия апа Гыйләҗева белән бергәләп эшләгән) туган җире – Самара өлкәсенең Камышлы районындагы Татар Байтуганы авылында торгызылган музей-йортта эш кайнап тора.

Санап бетерерлек түгел

Сәбәпләре дә бар. Беренчедән, бу байлыкны оештыручы Нурания ханым Абзалова күптән түгел музейлар буенча Бөтендөнья татар конгрессы үткәргән бәйгенең «Музей-мемориал» номинациясендә җиңү яулады. Икенчедән, авыл буенча берәмтекләп экспонат җыюдан башланган эшкә, ягъни музей-йортның сафка басуына биш ел вакыт үтеп киткән икән. Үзенә күрә кечкенә генә юбилей. Анысын да бик матур үткәргәннәр: Сәләй ага белән Рәмзия апа рухына Коръән укытканнар. Төрле җирләрдән кунаклар да күп килгән.

– Шушы еллар эчендә музей-йортта 7228 кеше булды, – дип үзенчә исәп-хисап ясый Нурания ханым. – Галимнәр, депутатлар, укытучылар, студентлар, сугыш ветераннары, журналистлар, артистлар – нинди генә һөнәр ияләре аяк басмаган икән Байтуганга. Хатирәләргә бирелеп, вакыт-вакыт тәкъдимнәр кенәгәсен актарырга яратам мин. Бөтен истәлекләр шунда җыелган бит инде. Кайлардан гына килмәгәннәр: Мәскәү, Санкт-Петербург, Казан, Сочи, Ульяновск, Чаллы, Самара, Уфа, Нижневартовск, Төмән, Оренбург, Тольятти, Сургут, Карачай-Черкес Республикасы… Кыскасы, санап бетерерлек түгел.

Байтуганда хәзер бер матур йола да яшәп килә: яшь парлар никахлашу, туй көннәрендә барча кунаклары белән музей-йортка юл тоталар. Беренче шундый пар Гөлия белән Филат Мингалиевлар була. Изге Әлифбадан юл алган бу гаилә быел агач туйларын билгеләп үткән. Әминә белән Дамир исемле ике бала үстерәләр.

– Без кунакларны музей-йорт янәшәсендәге коены сөлгеләр белән бизәп, тулы чиләкләр белән, бал һәм бавырсак каптырып каршы алабыз. Бик куаналар: авылда әби белән бабай янында кунакта булган кебек, диләр. Яшьләргә Сәләй ага белән Рәмзия апаның ачы язмышы турында сөйлибез. Үзенчә анысы да тәрбия дәресләре кебек бит инде, – ди Нурания ханым.

Йөрәгемне балаларга бирәм

Югыйсә Нурания ханым үзе дә белмәгән, авыл халкы да онытыбрак җибәргән була Сәләй ага хакында. Арада авыр еллар – ятимлек, Бөек Ватан сугышы, дошманга әсирлеккә эләккән өчен ГУЛАГка сөрелү, ике бала белән янына барган өчен Рәмзия апаның эштән куылуы, срогын бетереп чыккач та, Сәләй аганың эш таба алмый йөдәве, тагын әллә ниләр… Шулай булса да, сынмаган-сыгылмаган алар, гомерләре буена балалар өчен дәреслекләр иҗат иткәннәр. Димәк, йөрәк җылысы меңнәрчә балага җиткән.

Нурания ханым авылдашы турында очраклы гына ишетә. Медицина хезмәткәре буларак, район үзәгенә эш белән килеп чыккач, ТНВдан хәбәрләр карый. Шунда Сәләй аганың Арчада үткәрелгән юбилее турында сөйлиләр. Әлифба авторының Байтуганнан икәнлеген ишеткәч, гаҗәпләнүенә чик-чама булмый. Авылга кайткач, сорашып карый. Ятим малайны хәтерләүчеләр була әле, ә менә аның Әлифба авторы икәнлеген беркем дә белми. Нурания ханым туктап калмый, эзләнүләрне дәвам итеп, Арча көллиятенә хат язып сала. Сәләй ага ул чакта исән, әмма бик олы яшьтә була инде. Күп уйлап тормый, ире белән Арчага юл тота. Очрашалар, туйганчы бер сөйләшәләр. Сәләй ага, авылдашларым онытмаган икән бит, дип бик шатлана. «Минем йортым ни хәлдә икән?» – дигән сүзләр белән озатып кала. Хәрабәләр генә калган була шул мәчет янындагы бу нигездә. Нурания ханым ни дип җавап бирергә дә белми. Уйланып йөри торгач, ныклы бер карарга килә: шушы урында музей оештырырга. Сүзне үтәү бик җиңел булмый, әлбәттә. Әмма ул җиңеп чыга.

Алтын тауда – Әлифба

Музей эше азрак җайга салынгач, Нурания ханым башында тагын бер идея туа. Байтуган – ул тауларга бай дигән сүз. Әнә шул ерактан күренеп торган, Сәләй ага гел сагынып яшәгән тауларның берсенә – Алтын тау башына Әлифба сүзен яздырып куясы килә аның. Ерактан күреп, белеп торсыннар, дип уйлый. Теләк булгач, теләктәш тә табыла. Шулай бервакыт музейда мәктәп балалары белән Әнвәр Давыдовның 100 еллык бәйрәмен үткәрәләр. Кунакка Самарадагы «Туган тел» оешмасы президенты Ильяс Шәкүров та килә. Нурания аңа уй-хыялларын җиткерә, ярдәм итүен сорый. Нәтиҗәдә Алтын тау башында «Әлифба» пәйда була.

– Бу – Әлифбага һәйкәл кебек, – дип шатлана Нурания ханым. – Кыш көне хәрефләргә ак кар бөртекләре төшә, кайчак бәс белән каплана. Ерактан елтыр-елтыр килә. Ак төстә булгач, кара көз көннәрендә маяк кебек янып тора. Әйтерсең лә, юл күрсәтә. Без аны хәзер Әлифба тавы дип йөртәбез. Бу һәйкәлне ачу тантанасына 28 төбәктән 500ләп кеше килгән иде. Балалар татарча шигырьләр сөйләделәр. Кунакларны татар ашлары белән сыйлап, хуш исле бал белән күмер самавырларыннан чәй эчерттек. Авыл халкы өчен дә зур бәйрәм булды ул. Гармун моңнарын тыңлап, биешеп, җырлашып мәш килделәр. Елашып та алдылар. Бер тапкыр Сәләй аганың улы Камил абый белән шул тауга җиләккә дә барган идек. Бик күп истәлекләр сөйләде. Ул әтисен беренче тапкыр 6 яшендә күргән. «Әти миңа Байтуганның җиләкле аланнары турында сөйли иде дә, күзләре яшьләнеп: «Әй, мин сиңа ни дип сөйлим инде, барыбер бервакытта да кайта алмассың, күрә алмассың инде син аларны», – дип әйтә иде. Әтиемнең бик күрәсе килде туган авылын. Тауларны, урам-тыкрыкларны берәмтекләп искә алып утыра иде. Аның монда кайта алмавы репрессиягә кагылышлы мөнәсәбәтләргә бәйле иде, аннан олыгаеп, сәламәтлеге какшап китте», – дип искә ала ул.

Кайта Камил абый, Нурания ханым чакыруы буенча дүрт тапкыр була әтисенең туган авылында. Музейга дип шактый гына экспонатлар да тапшыра.

…Нурания укырга кергән елны Татар Байтуганында татар мәктәбен ябалар. Укучылар, елый-елый, Рус Байтуганындагы рус мәктәбенә юл тоталар. Әмма авыл татарлыгын югалтмый. Элек тә шулай булган. Әлифба музей-йорты эшләп торгач, хәзер инде бигрәк тә. Бәлки безгә телебезне, гореф-гадәтләребезне югалтмас өчен, чыннан да, халыкны магнит кебек тартып торучы шундый урыннар, Нурания кебек актив кешеләр җитешеп бетмидер.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Шөгыль

КӘРҖИН ҮРҮЧЕ РУФИЯ ШАКИРОВА:

«АКМАСА ДА, ТАМЫП ТОРА»

Арча районының Казанбаш авылында гомер итүче Руфия Шакированы кул эшләренә дәү әнисе өйрәтеп калдыра. Кыз кечкенәдән бәйләргә, чигәргә оста була. Аннары инде тормыш мәшәкатьләре белән кул эше читкәрәк күчеп тора. Гомере буе балалар укыта ул.

Руфия апа 65 яшенә кадәр мәктәптә эшли. Әле лаеклы ялга чыкканына бер генә ел. Ә менә кызы белән бергәләп кәрҗин үрергә тотынуларына 4 ел икән инде.

– Үзебезгә суган, бәрәңге салып куяр өчен кәрҗин кирәк булды. Без аны икенчел чималдан, төзелеш кибетләрендә сатыла торган полипропилен тасмадан үрәбез. Чималны күп итеп алып куябыз да рәхәтләнеп эшлибез. Хуҗалыкта нәрсә салам дисәң, шуңа ярый ул. Җиләкләрне дә шуңа җыябыз хәзер, гөмбәгә дә ярап куя, йомырканы да шунда тотабыз. Иң мөһиме – ул кәрҗин һава йөртә.

Кул эшләрен интернетка куеп бара алар. Әнә шуннан күреп, заказ бирүчеләр дә арткан.

– Соңгы арада туйларга күчтәнәчләр салып барыр өчен пар итеп эшләтеп алалар. Нинди үлчәмдә кирәк, шундыен ясап бирәбез. Бәяләрне кыйммәт итмибез. Иң кечкенәсе – 150, зурысы 600 сум йөри. Сорап эшләтүчеләр булгач, рәхәт. Матди яктан да ярдәм итә. Эшләгән акчам көндәлек кирәк-яракка җитә, – ди Руфия апа. – Бер дә кыен эш түгел. Теләгең генә булсын. Хәзер бит интернетта барысы да бар. Шуннан карап өйрәндек. Кеше ниндиен сорый, шулай итеп үреп бирәбез. Иң мөһиме – халыкка ошасын. Бик ашыгыч заказ була икән, аны көнендә үк эшлибез. Туйга дигән кәрҗиннәрне 1,5 сәгать эчендә ясап була.

Руфия апа быел үзләренә игътибар артканын яшерми. Республикада өлкәннәр арасында узучы «Халык иҗаты» бәйгесендә катнашкач, аларны танып белүчеләр күбәйгән. Кәрҗиннәрне бүләккә дә, үзләренә кулланыр өчен дә сораучылар бар икән.

– Кышын тик утырмадык. Язын, җәен бакчада эш күп инде. Әмма яраткан шөгыльгә вакыт табарбыз дип уйлыйм, – ди ул. – Вакытның бер генә минутын да әрәм итәсем килми. Телевизор карарга утырсам, кулга берәр эш тотам. Урындыкка җәймә булса да бәйләп утырам мин. Татар халкы элек-электән кул эше белән яшәгән. Шөкер, безнең якларда әби-бабаларыбыз эшен дәвам итүчеләр күп. Шунысы сөендерә: кул эшенә балалар да тартыла. Безгә шул кирәк тә – киләчәк буын һөнәрле булып үссен!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 7066 данә
Гомуми тираж – 16091 данә
Газетага сертификат бирелде
Заказ 247

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+